| | |
|---|---|
| СОВЕТ<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ<br>«ГЛАЗОВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ<br>ПОСЕЛЕНИЕ»<br>ЛЕНИНОГОРСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЛЕНИНОГОРСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ГЛАЗОВО<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»<br>МУНИЦИПАЛЬ<br>БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ |
| РЕШЕНИЕ | КАРАР |
| 2026 елның 6 апреле | № 6 |

«Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының
аерым карарларының үз көчләрен югалтуын тану турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 28 декабрендәге 505-ФЗ номерлы Федераль законга һәм «Россия Федерациясе Президентының кайбер актларын үзгәртү һәм үз көчләрен югалтуын тану турында» 2025 елның 31 декабрендәге 1009 номерлы Россия Федерациясе Президенты Указына 2 нче кушымтаның 15 пунктына таянып, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының түбәндәге карарларының үз көчен югалтуын танырга:

01.08.2017 ел, № 17 «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тапшырылган керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан бастырып чыгару өчен бирү тәртибен раслау турында»;

17.05.2022 № 10 «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Советының 2017 елның 1 августындагы 17 номерлы карары белән расланган, муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру һәм Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Глазово авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм контракт буенча башкарма комитет җитәкчесе вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан тәкъдим ителгән керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бастыру өчен бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү турында».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Урнәк-Кумәк авылы, Мәктәп урамы, 3А йорты адресы буенча урнашкан үзидарә администрациясе бинасында; Глазово авылы, Заречная урамы, 13 йорты; Петропавловка авылы, Горький урамы, 19А йорты адреслары буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында (https://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан

Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында (https://pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

«Глазово авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы,
Совет рәисе — Н.К.Карабаева